КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 12 сентябрь № 668

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының урта һөнәр белеме бирүче дәүләт учреждениеләрендә урта һөнәр белеме һөнәрләре (белгечлекләре) буенча квалификацияле кадрларны максатчан әзерләү турында» 2013 ел, 29 июнь, 453 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының урта һөнәр белеме бирүче дәүләт учреждениеләрендә урта һөнәр белеме һөнәрләре (белгечлекләре) буенча квалификацияле кадрларны максатчан әзерләү турында» 2013 ел, 29 июнь, 453 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 23 декабрь, 1032 нче; 2014 ел, 3 сентябрь, 637 нче; 2014 ел, 24 сентябрь, 671 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карарга теркәлгән 1 нче кушымтада:

14 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «14 | «Казан коммуналь хуҗалык һәм төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәр белеме бирү учреждениесе; |

кушымтага түбәндәге эчтәлекле 15 – 18 нче пунктлар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «15 | «Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумы» дәүләт автоном һөнәр белеме бирү учреждениесе |
| 16 | «Лениногорск нефть техникумы» дәүләт автоном һөнәр белеме бирү учреждениесе |
| 17 | «Кама дәүләт автомеханика техникумы» дәүләт автоном һөнәр белеме бирү учреждениесе |

| | |
|---|---|
| 18 | «Казан төзелеш көллияте» дәүләт бюджет һөнәр белеме бирү учреждениесе; |

әлеге карарга теркәлгән 2 нче кушымтада:
3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «3 | Станокчы (металл эшкәртү) | 25 | 25 | 45»; |

6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «6 | Йорт һәм коммуналь хуҗалык сервисы | 50 | 50 | 10»; |

8 – 14 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «8 | Эчке сантехника, кондиционер ярдәмендә һаваны җилләтү һәм вентиляцияләү җайланмаларын монтажлау һәм эксплуатацияләү | 25 | 25 | 0 |
| 9 | Электрон приборлар һәм җайланмалар | 25 | 20 | 0 |
| 10 | Компьютер челтәрләре | 25 | 10 | 0 |
| 11 | Радиотехник мәгълүмат системалары | 25 | 20 | 0 |
| 12 | Компьютер системалары һәм комплекслары | 25 | 25 | 0 |
| 13 | Технологик процессларны һәм җитештерүне автоматлаштыру (тармаклар буенча) | 25 | 25 | 0 |
| 14 | Механик эшкәртүдә станоклар һәм җиһазлар көйләүче | 0 | 25 | 0»; |

кушымтага түбәндәге эчтәлекле 15 – 22 нче пунктлар өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «15 | Токарь-универсал | 0 | 0 | 15 |
| 16 | Технологик насослар һәм компрессорлар машинисты | 0 | 0 | 25 |
| 17 | Очу аппаратларын җитештерү | 0 | 0 | 25 |
| 18 | Машина төзелеше технологиясе | 0 | 0 | 25 |
| 19 | Автомат идарә итү системалары | 0 | 0 | 25 |
| 20 | Сәнәгать җиһазларын монтажлау һәм техник эксплуатацияләү | 0 | 0 | 25 |
| 21 | Коры төзелеш мастеры | 0 | 0 | 15 |
| 22 | Металл булмаган төзелеш эшләнмәләрен һәм конструкцияләрен җитештерү | 0 | 0 | 15». |

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә әлеге карар үз көченә кергәннән соң 30 көн эчендә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмаларында квалификацияле кадрларны максатчан әзерләүне тормышка ашыруга хезмәт күрсәтүләрнең күләмнәре нормативларын һәм норматив чыгымнарын раслау турында» 2015 ел, 19 март, 164 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карар проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Бу карарның гамәле 2015 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\668.docx